КАБИНЕТ МИНИСТРОВ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2018 ел, 31 октябрь г.Казань № 974

Күпфатирлы йортларны һәм (яки) бүтән күчемсез милек объектларын өлешле төзү өлкәсендә, шулай ук Татарстан Республикасы территориясендә күпфатирлы йортлар төзү белән бәйле торак-төзелеш кооперативлары эшчәнлегенә төбәк дәүләт контролен (күзәтчелеген) оештыру һәм гамәлгә ашыру тәртибен раслау турында

«Дәүләт контролен (күзәтчелеген) һәм муниципаль контрольне гамәлгә ашырганда юридик затлар һәм шәхси эшмәкәрләр хокукларын яклау турында» 2008 елның 26 декабрендәге 294-ФЗ номерлы Федераль закон, Россия Федерациясе Хөкүмәтенең «Дәүләт контроленең (күзәтчелегенең) аерым төрләрен оештырганда куркынычка юнәлдерелгән якын килүне куллану һәм Россия Федерациясе Хөкүмәтенең кайбер актларына үзгәрешләр кертү турында» 2016 ел, 17 август, 806 нчы карары нигезендә Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

1. Карарга теркәлгән Күпфатирлы йортларны һәм (яки) бүтән күчемсез милек объектларын өлешле төзү өлкәсендә, шулай ук Татарстан Республикасы территориясендә күпфатирлы йортлар төзү белән бәйле торак-төзелеш кооперативлары эшчәнлегенә төбәк дәүләт контролен (күзәтчелеген) оештыру һәм гамәлгә ашыру тәртибен расларга.

2. Бу карарның үтәлешен тикшерүдә тотуны Татарстан Республикасы Дәүләт төзелеш күзәтчелеге инспекциясенә йөкләргә.

Татарстан Республикасы
Премьер-министры А.В.Песошин

Татарстан Республикасы
Министрлар Кабинетының
2018 ел, 31 октябрь, 974 нче
карары белән расланды

Күпфатирлы йортларны һәм (яки) бүтән күчемсез милек объектларын өлешле төзү өлкәсендә, шулай ук Татарстан Республикасы территориясендә күпфатирлы йортлар төзү белән бәйле торак-төзелеш кооперативлары эшчәнлегенә төбәк дәүләт контролен (күзәтчелеген) оештыру һәм гамәлгә ашыру
тәртибе

Гомуми нигезләмәләр

1. Әлеге Тәртип Күпфатирлы йортларны һәм (яки) бүтән күчемсез милек объектларын өлешле төзү өлкәсендә, шулай ук Татарстан Республикасы территориясендә күпфатирлы йортлар төзү белән бәйле торак-төзелеш кооперативлары эшчәнлегенә төбәк дәүләт контролен (күзәтчелеген) оештыру һәм гамәлгә ашыруга таләпләрне (алга таба – Тәртип) билгели.

2. Күпфатирлы йортларны һәм (яки) бүтән күчемсез милек объектларын өлешле төзү өлкәсендә, шулай ук Татарстан Республикасы территориясендә күпфатирлы йортлар төзү белән бәйле торак-төзелеш кооперативлары эшчәнлегенә төбәк дәүләт контроле (күзәтчелеге) (алга таба – Татарстан Республикасы территориясендә өлешле төзү өлкәсендә төбәк дәүләт контроле (күзәтчелеге)) әлеге Тәртип нигезендә түбәндәгеләр тарафыннан гамәлгә ашырыла:

«Татарстан Республикасы муниципаль районнары һәм шәһәр округлары җирле үзидарә органнарына күпфатирлы йортларны һәм (яисә) күчемсез мөлкәтнең бүтән объектларын өлешле төзү өлкәсендә дәүләт тикшереп торуын һәм күзәтчелеген гамәлгә ашыру буенча Татарстан Республикасы дәүләт вәкаләтләрен бирү турында» 2007 елның 27 декабрендәге 66-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының (алга таба – 66-ТРЗ номерлы ТР Законы) 2 статьясында күрсәтелгән Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләрендә Татарстан Республикасы муниципаль районнары һәм шәһәр округлары җирле үзидарә органнары;

аларга карата 66-ТРЗ номерлы ТР Законы гамәле туктатылган аерым муниципаль берәмлекләрдә Татарстан Республикасы Дәүләт төзелеш күзәтчелеге инспекциясе (алга таба – контрольдә тотучы органнар).

3. Татарстан Республикасы территориясендә өлешле төзелеш өлкәсендә төбәк дәүләт контролен (күзәтчелеген) гамәлгә ашырганда аларга карата контроль буенча чаралар гамәлгә ашырылган затлар күпфатирлы йортлар төзү белән бәйле төзүче, торак-төзелеш кооперативы булалар (алга таба – күпфатирлы йортларны һәм (яки) бүтән күчемсез милек объектларын өлешле төзү өчен гражданнар акчасын җәлеп итүче затлар).

4. Татарстан Республикасы территориясендә өлешле төзелеш өлкәсендә төбәк дәүләт контроле (күзәтчелеге) предметы булып төзүчеләр тарафыннан «Күпфатирлы йортларны һәм (яисә) күчемсез мөлкәтнең бүтән объектларын өлешле төзүдә

катнашу турында һәм Россия Федерациясенең кайбер закон актларына үзгәрешләр кертү хакында» 2004 елның 30 декабрендәге 214-ФЗ номерлы Федераль законда һәм аның нигезендә кабул ителгән бүтән норматив хокукый актларда билгеләнгән мәҗбүри таләпләрне саклау, торак-төзелеш кооперативы тарафыннан Россия Федерациясе Торак кодексының 110 статьясындагы 3 өлеш (күпфатирлы йортларны алга таба карап тотудан тыш) һәм Россия Федерациясе Торак кодексының 123.1 статьясы белән билгеләнгән мәҗбүри таләпләрне (алга таба – мәҗбүри таләпләр) саклау тора.

5. Татарстан Республикасы территориясендә өлешле төзелеш өлкәсендә төбәк дәүләт контроле (күзәтчелеге) түбәндәгеләр ярдәмендә гамәлгә ашырыла:

күпфатирлы йортларны һәм (яки) бүтән күчемсез милек объектларын өлешле төзү өчен гражданнар акчасын җәлеп итүче затлар эшчәнлеген мәҗбүри таләпләрне үтәү буенча документар һәм (яки) күчмә тикшерүләр рәвешендә планлы яки планнан тыш тикшерүләр;

мәҗбүри таләпләрне бозуларны профилактикалау буенча чаралар үткәрү;

юридик затлар, шәхси эшмәкәрләр белән багланышларсыз гамәлгә ашырыла торган контроль чараларын үткәрү;

бозуларны кисәтү һәм (яки) ачыкланганнары нәтиҗәләрен бетерү буенча Россия Федерациясе законнарында каралган чаралар күрү;

мәҗбүри таләпләрне үтәүне системалы күзәтү;

юридик затлар, шәхси эшмәкәрләр эшчәнлеген гамәлгә ашырганда мәҗбүри таләпләрне үтәү торышын анализлау һәм фаразлау.

6. Татарстан Республикасы территориясендә өлешле төзелеш өлкәсендә төбәк дәүләт контролен (күзәтчелеген) гамәлгә ашырганда юридик затлар һәм шәхси эшмәкәрләр эшчәнлегенә куркынычка юнәлдерелгән якын килүне куллану максатларында Россия Федерациясе Хөкүмәтенең «Дәүләт контроленең (күзәтчелегенең) аерым төрләрен оештырганда куркынычка юнәлдерелгән якын килүне куллану һәм Россия Федерациясе Хөкүмәтенең кайбер актларына үзгәрешләр кертү турында» 2016 ел, 17 август, 806 нчы карары белән расланган Юридик затлар һәм шәхси эшмәкәрләр эшчәнлеген һәм (яки) алар куллана торган җитештерү объектларын билгеле бер куркыныч категориясенә яки куркынычның билгеле бер классына (категориясенә) кертү кагыйдәләре һәм әлеге Тәртип нигезендә куркынычның билгеле бер категориясенә кертелергә тиеш.

Юридик затлар, шәхси эшмәкәрләр эшчәнлеген куркыныч категорияләренә кертү Татарстан Республикасы территориясендә өлешле төзелеш өлкәсендә төбәк дәүләт контролен (күзәтчелеген) гамәлгә ашырганда юридик затлар, шәхси эшмәкәрләр тарафыннан мәҗбүри таләпләрне үтәүмәнең мөмкин булган тискәре нәтиҗәләрен исәпкә алып, куркыныч күрсәткече нигезендә гамәлгә ашырыла.

Юридик затлар, шәхси эшмәкәрләр тарафыннан мәҗбүри таләпләрне үтәүмәнең мөмкин булган тискәре нәтиҗәләрен исәпкә алып куркыныч күрсәткече һәм юридик затлар, шәхси эшмәкәрләр тарафыннан мәҗбүри таләпләрне үтәмәү мөмкинлекләре түбәндәге таблицада китерелгән критерияләр нигезендә билгеләнә.

Таблица

Татарстан Республикасы территориясендә өлешле төзелеш өлкәсендә төбәк дәүләт контролен (күзәтчелеген) гамәлгә ашырганда юридик затлар һәм шәхси эшмәкәрләр эшчәнлеген аерым куркыныч категорияләренә кертү критерияләре

| Татарстан Республикасы территориясендә өлешле төзелеш өлкәсендә төбәк дәүләт контроле (күзәтчелеге) объектлары | Куркыныч категорияләре |
|---|---|
| 1 | 2 |
| I. Мәҗбүри таләпләр үтәмәүнең мөмкин булган тискәре нәтиҗәләре авырлыгы һәм мәҗбүри таләпләрне үтәмәү мөмкинлеге критерийләре | |
| Әлеге таблицаның II бүлегендә каралган күпфатирлы йортларны һәм (яки) бүтән күчемсез милек объектларын өлешле төзү өчен гражданнар акчасын җәлеп итү буенча юридик затлар һәм шәхси эшмәкәрләр эшчәнлеге | түбән куркыныч |
| II. Мәҗбүри таләпләрне үтәмәү мөмкинлеге критерийләре | |
| 1. Күпфатирлы йортларны һәм (яки) бүтән күчемсез милек объектларын өлешле төзү өчен гражданнар акчасын җәлеп итү буенча эшчәнлекне гамәлгә ашыручы юридик затлар һәм шәхси эшмәкәрләр:<br>төзүчегә карата банкротлык процедураларының берсен алып барганда;<br>куркыныч категориясен бирү турында карар кабул иткән көнгә өлешле төзелештә катнашу шартнамәләре буенча йөкләмәләрне үтәү вакыты 6 айдан озак вакытка бозылу фактлары булганда;<br>төзүченең устав капиталы күләме законнар таләпләренә туры килмәгәндә (2017 елның 1 июленнән соң);<br>квартал хисабын анализлау нәтиҗәләре буенча ачыкланган өлешле төзелештә катнашучыларның акчасын объект төзелешенең планлаштырылган смета бәясе 20 проценттан артык күләмдә максатка ярашсыз файдалану билгеләре булганда (агымдагы һәм алдагы календарь елы чорына);<br>финанс тотрыклылыгының барлык нормативларын сакламаганда (агымдагы һәм алдагы календарь елы чорына);<br>Россия Федерациясе Хөкүмәтенең «Өлешле төзелештә катнашучыларның акчасын җәлеп итү белән бәйле эшчәнлекне гамәлгә ашыру буенча төзүчеләрне квартал хисабы турында» 2005 ел, 27 октябрь, 645 нче карары (алга таба – Хөкүмәтнең постановление Правительства РФ № 645), РФ Төзелеш һәм торак-коммуналь хуҗалык министрлыгының «Күпфатирлы йортларны һәм (яки) бүтән | сизелерлек куркыныч |

| 1 | 2 |
|---|---|
| күчемсез милек объектларын өлешле төзү өчен гражданнар акчасын җәлеп итү белән бәйле торак-төзелеш кооперативы эшчәнлеген гамәлгә ашыру турында хисаплылык формасын, шул исәптән мондый кооператив тарафыннан кооператив әгъзалары һәм бүтән затлар алдында үз йөкләмәләрен үтәү турында һәм торак-төзелеш кооперативы тарафыннан күрсәтелгән хисаплылыкны Россия Федерациясе субъектының күпфатирлы йортларны һәм (яки) бүтән күчемсез милек объектларын өлешле төзү өлкәсендә дәүләт контролен (күзәтчелеген) гамәлгә ашыручы органга тапшыру тәртибен раслау хакында» 2017 ел, 3 июль, 955/б номерлы боерыгы (алга таба – РФ Төзелеш министрлыгының 955/б номерлы боерыгы) таләпләре нигезендә юридик затның мондый хисаплылык бирү йөкләмәсе барлыкка килгәндә бер-бер артлы ике хисап чорында төзүче, торак-төзелеш кооперативы махсуслашкан хисаплылык бирмәгәндә;<br>төзүченең генераль директорын һәм (яки) баш хисапчысын икътисад өлкәсендә җинаятьләр өчен җинаять җаваплылыгына тартканда;<br>зат Россия Федерациясе Административ хокук бозулар турында кодексының 14.28 статьясындагы 1, 4 өлешләр, 19.5 статьясындагы 4 өлеш буенча административ җәзага тартылган дип саналган вакытны исәпкә алып, куркыныч категориясенә кертү турында карар кабул ителгән көнгә юридик затны, вазыйфаи затны яки шәхси эшмәкәрне административ җаваплылыкка тарту факты булганда;<br>күпфатирлы йортны һәм (яки) бүтән күчемсез милек объектын төзү (булдыру) өчен бары тик залогка бирелгән җир кишәрлеген яки әлеге җир кишәрлегенә һәм әлеге җир кишәрлегендә төзелә (булдырыла) торган күпфатирлы йортка һәм (яки) бүтән күчемсез милек объектына аренда хокукын, субаренда хокукын өлешле төзелештә катнашу шартнамәләре буенча төзүче йөкләмәләрен үтәүне тәэмин иткәндә | |
| 2. Күпфатирлы йортларны һәм (яки) бүтән күчемсез милек объектларын төзү өчен гражданнарның акчаларын җәлеп итү буенча эшчәнлекне гамәлгә ашыручы юридик затлар һәм шәхси эшмәкәрләр:<br>куркыныч категориясен бирү турында карар кабул иткән көнгә өлешле төзелештә катнашу шартнамәләре буенча йөкләмәләрне үтәү вакыты 90 көннән кимрәк вакытка бозылу фактлары булганда;<br>төзүченең узган календарь елы өчен төзүче активларының | уртача куркыныч |

| 1 | 2 |
|---|---|
| баланс бәясенең 25 процентыннан артык күләмдә Россия Федерациясе бюджет системасы бюджетларына салымнар, җыемнар буенча түләнми калган өлеше, бүтән мәҗбүри түләүләр буенча бурычлары булганда;<br>ике яки артыграк эзлекле хисап чорлары дәвамында финанс тотрыклыгы нормативларының берсен үтәмәгәндә (агымдагы һәм алдагы календарь елы чоры өчен);<br>квартал хисабын анализлау нәтиҗәләре буенча ачыкланган өлешле төзелештә катнашучыларның акчасын объект төзелешенең планлаштырылган смета бәясенең 5 тән 20 процентка кадәр күләмдә максатка ярашсыз файдалану билгеләре булганда (агымдагы һәм алдагы календарь елы чорына);<br>төзүченең генераль директорын һәм (яки) баш хисапчысын икътисад өлкәсендә җинаятьләр өчен җинаять җаваплылыгына тарту турында җинаять эше кузгату турында мәгълүматлар булганда;<br>йөкләмәләр үтәү һәм (яки) объектаня эксплуатациягә кертү вакытларын күчерү хакында өлешле төзелештә катнашучыларга хәбәр итү вакытларын бозганда (агымдагы һәм алдагы календарь елы чорына);<br>контрольдә тотучы орган тарафыннан законнар бозуны бетерү турында икедән артык боерык (кисәтү) чыгарылган очракта (агымдагы һәм алдагы календарь елы чорына);<br>контрольдә тотучы органга өлешле төзелеш өлкәсендә законнарның мәҗбүри таләпләрен бозуның расланган фактлары турында гражданнар, шул исәптән шәхси эшмәкәрләр, юридик затлар мөрәҗәгатьләре һәм гаризалары, дәүләт хакимияте органнарыннан, җирле үзидарә органнарыннан, массакүләм мәгълүмат чараларыннан, «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәреннән мәгълүмат кергәндә (агымдагы һәм алдагы календарь елы чорына);<br>төзүчене намуссыз сатучылар (подрядчылар, үтәүчеләр) реестрына керткәндә («Юридик затларның аерым төрләре тарафыннан товарлар, эшләр, хезмәт күрсәтүләр сатып алу турында» 2011 елның 18 июлендәге 223-ФЗ номерлы, «Дәүләт һәм муниципаль ихтыяҗларны тәэмин итү өчен товарлар, эшләр, хезмәт күрсәтүләр өлкәсендә контракт системасы турында» 2013 елның 5 апрелендәге 44-ФЗ номерлы федераль законнар буенча);<br>төзүчене дәүләт һәм муниципаль милектәге җир кишәрлеген сату буенча аукционда яисә дәүләт һәм муниципаль милектәге җир кишәрлеге арендасы | |

| 1 | 2 |
|---|---|
| шартнамәсен төзү хокукына аукционда намуссыз катнашучылар реестрына керткәндә;<br>юридик затның РФ Хөкүмәтенең 645 нче карары, РФ Төзелеш министрлыгының 955/б номерлы боерыгы таләпләре нигезендә хисаплылык бирү буенча йөкләмәләре барлыкка килгән вакыттан алып бер хисап чорына төзүче мондый махсуслашкан хисапны тапшырмаганда;<br>куркыныч категориясенә кертү турында карар кабул иткән көнгә Россия Федерациясе Административ хокук бозулар турында кодексының 14.28 статьясындагы 2 һәм 3 өлешләр, 13.19.3 һәм 14.28.1 статьялар буенча административ җәзага тартылган дип саналган вакытны исәпкә алып, куркыныч категориясенә кертү турында карар кабул ителгән көнгә юридик затны, вазыйфаи затны яки шәхси эшмәкәрне административ җаваплылыкка тарту факты булганда;<br>өлешле төзелештә катнашу шартнамәләре буенча, залог белән бергә, төзүче йөкләмләрен үтәүне тәэмин иткәндә төзүченең гражданлык җаваплылыгын иминиятләү яки банк җаваплылыгы белән. | |

6.1. Юридик затлар, шәхси эшмәкәрләр гамәлгә ашыра торган эшчәнлекне куркыныч категорияләренә кертү һәм аны куркыныч категорияләренең берсенә кертү турында карарны яңадан карау ел саен, агымдагы елның 1 августына кадәр контрольдә тотучы орган җитәкчесе карары белән гамәлгә ашырыла.

6.2. Юридик затлар, шәхси эшмәкәрләр эшчәнлеген түбән куркыныч категориясенә кертү таблицаның II бүлегендә каралган шартлар булмаганда, урта һәм сизелерлек куркыныч категориясенә кертү таблицаның II бүлегендә каралган юридик затлар, шәхси эшмәкәрләр эшчәнлеген билгеле бер куркыныч категориясенә кертү критерийләре булганда гамәлгә ашырыла.

6.3. Юридик затны, шәхси эшмәкәрне куркынычның төрле категорияләренә кертү мөмкинлеген бирә торган критерийләр булганда куркынычның югарырак категориясенә карый торган критерий кулланылырга тиеш.

6.4. Юридик затлар, шәхси эшмәкәрләр эшчәнлеген куркынычның билгеле бер категориясенә кертү турында карар булмаганда алар эшчәнлеге түбән куркыныч категориясенә кертелгән булып санала.

6.5. Юридик затларга, шәхси эшмәкәрләргә карата планлы тикшерүләр үткәрү аларның өлешле төзелеш өлкәсендәге эшчәнлегенә бирелгән куркыныч категориясенә бәйле түбәндәге кабатланып тору белән гамәлгә ашырыла:

сизелерлек куркыныч категорияләре өчен – елга бер тапкыр;

урта куркыныч категорияләре өчен – ике елга бер тапкырдан артык түгел;

түбән куркыныч категорияләре өчен – планлы тикшерүләр үткәрелми.

6.6. Контрольдә тотучы органнар эшчәнлекләре куркыныч категориясенә кертелгән юридик затлар, шәхси эшмәкәрләр исемлеген (алга таба – Исемлек) алып бара.

Исемлеккә кертү контрольдә тотучы орган җитәкчесенең юридик затлар, шәхси эшмәкәрләр гамәлгә ашыра торган эшчәнлекне тиешле куркыныч категорияләренә кертү турында карары нигезендә әлеге карар кабул ителгән көннән соң өч эш көне эчендә гамәлгә ашырыла.

6.7. Исемлек түбәндәге мәгълүматны үз эченә ала:

куркыныч категориясе бирелгән затның тулы исеме;

төп дәүләт теркәү саны;

салым түләүченең шәхси саны;

затның урнашу урыны;

куркыныч категориясенә күрсәтмә, зат эшчәнлеген куркыныч категориясенә кертү турында карар реквизитлары, шулай ук алар нигезендә әлеге карар кабул ителгән мәгълүматлар.

6.8. Контрольдә тотучы органның «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге рәсми сайтында эшчәнлекләре Исемлектәге сизелерлек куркыныч категориясенә кертелгән юридик затлар, шәхси эшмәкәрләр турында түбәндәге мәгълүматны урнаштырыла һәм актуаль хәлдә тотыла:

затның тулы исеме;

төп дәүләт теркәү саны;

затның урнашу урыны;

куркыныч категориясенә күрсәтмә, өлешле төзелеш өлкәсендәге төзүче, торак-төзелеш кооперативы эшчәнлеген куркыныч категориясенә кертү турында карар кабул ителгән көн.

Югарыда күрсәтелгән мәгълүматны урнаштыру дәүләт серен саклау турында Россия Федерациясе законнарын исәпкә алып гамәлгә ашырыла.

6.9. Юридик зат, шәхси эшмәкәр соравы буенча контрольдә тотучы орган әлеге зат эшчәнлегенә куркыныч категориясе бирү турында мәгълүматны, шулай ук аның эшчәнлеген куркынычның билгеле бер төренә керткәндә файдаланылган белешмәләрне тапшыра.

6.10. Юридик зат, шәхси эшмәкәр элек бирелгән куркыныч категориясен үзгәртү турында контрольдә тотучы органга гариза тапшырырга хокуклы.

7. Татарстан Республикасы территориясендә өлешле төзелеш өлкәсендә төбәк дәүләт контролен (күзәтчелеген) гамәлгә ашырганда административ процедураланы үтәү вакытлары һәм эзлеклелеге, Татарстан Республикасы территориясендә өлешле төзелеш өлкәсендә төбәк дәүләт контролен (күзәтчелеген) гамәлгә ашырырга вәкаләтле вазыйфаи затлар исемлеге контрольдә тотучы органнарның тиешле хокукый актлары белән расланган Күпфатирлы йортларны һәм (яки) бүтән күчемсез милек объектларын өлешле төзү өлкәсендә, шулай ук күпфатирлы йортлар төзү белән бәйле торак-төзелеш кооперативлары эшчәнлегенә төбәк дәүләт контролен (күзәтчелеген) оештыру буенча дәүләт функцияләрен үтәүнең административ регламентлары белән билгеләнә.

8. Контрольдә тотучы органнарның вазыйфаи затлары Татарстан Республикасы территориясендә өлешле төзелеш өлкәсендә төбәк дәүләт контролен (күзәтчелеген) гамәлгә ашырганда «Дәүләт контролен (күзәтчелеген) һәм муниципаль контрольне гамәлгә ашырганда юридик затлар һәм шәхси эшмәкәрләр хокукларын яклау турында» 2008 елның 26 декабрендәге 294-ФЗ номерлы Федераль

законда, «Күпфатирлы йортларны һәм (яисә) күчемсез мөлкәтнең бүтән объектларын өлешле төзүдә катнашу турында һәм Россия Федерациясенең кайбер закон актларына үзгәрешләр кертү хакында» 2004 елның 30 декабрендәге 214-ФЗ номерлы Федераль законда һәм Россия Федерациясе Торак кодексының 123.2 статьясында билгеләнгән чикләүләрне сакларга һәм йөкләмләрне үтәргә тиеш.

9. Татарстан Республикасы территориясендә өлешле төзелеш өлкәсендә төбәк дәүләт контролен (күзәтчелеген) гамәлгә ашырырганда контрольдә тотучы органнарның вазыйфаи затлары Татарстан Республикасы прокуратурсы органнары, экспертлар, эксперт оешмалар, юридик затлар, шәхси эшмәкәрләр белән үзара багланышларга керә.

Тикшерүләр үткәрүгә аларга карата тикшерүләр алып барыла торган юридик затлар, шәхси эшмәкәрләр белән граждан-хокукый һәм хезмәт мөнәсәбәтләрендә тормаган һәм тикшерелә торан затларның аффиләшкән затлары булмаган Россия Федерациясе Хөкүмәте билгеләгән тәртиптә аттестацияләнгән экспертлар, илкүләм аккредитация системасында аккредитацияләү турында Россия Федерациясе законнары нигезендә аккредитацияләнгән эксперт оешмалары җәлеп ителә ала.

10. Тикшерүләр үткәргәндә контрольдә тотучы органнарның вазыйфаи затлары гамәлләренә (гамәл кылмауларына) Россия Федерациясе законнары нигезендә административ һәм (яки) суд тәртибендә шикаять белдерелергә мөмкин.